КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 27 июль г.Казань № 898

«Татарстан Республикасының Кластерлы үсеш һәм проект буенча идарә итү үзәге» коммерциягә карамаган автоном оешмасының күзәтү советына Татарстан Республикасы вәкилен билгеләү турында

«Коммерциягә карамаган оешмалар турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Гамәлгә куючысы Татарстан Республикасы булган автоном коммерциягә карамаган оешмаларның идарә органнарында Татарстан Республикасы вәкилләре катнашу тәртибен раслау турында» 2015 ел, 26 июнь, 466 нчы карары нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. «Татарстан Республикасының Кластерлы үсеш һәм проект буенча идарә итү үзәге» коммерциягә карамаган автоном оешмасының күзәтү советына Татарстан Республикасы икътисад министрының беренче урынбасары – Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының Эшмәкәрлекне һәм конкуренцияне үстерү департаменты директоры Кондратова Наталья Владимировнаны Татарстан Республикасы вәкиле итеп билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Кластерлы үсеш һәм проект буенча идарә итү үзәге» коммерциягә карамаган автоном оешмасының күзәтү советына Татарстан Республикасы вәкилен билгеләү турында» 2022 ел, 7 ноябрь, 1182 нче карарын үз көчен югалткан дип танырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин